ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяда:
а) 2 өлештә:
1 пунктта «электрон документ рәвешендә» сүзләрен «электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;
2 пунктта «электрон документ рәвешендә» сүзләрен «электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:
«4. Архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм җирле үзидарә органнары Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә архив документларын һәм аларга кагылышлы белешмә-эзләү чараларын ерактан торып карау һәм алардан файдалану хезмәтен (алга таба – архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәте) күрсәтү өчен кирәкле оештыру-техник һәм башка шартлар булдырырга хокуклы.»;

2) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 – 8 өлешләр өстәргә:
«6. Татарстан Республикасы дәүләт архивларында саклана торган архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен күрсәтү архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә тәэмин ителә.
7. Муниципаль архивлар аларда саклана торган архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

тарафыннан билгеләнгән тәртиптә архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә күрсәтергә хокуклы.

8. Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертелгән, архив тарафыннан электрон рәвешкә күчерелгән архив документларының электрон күчермәләрен карау һәм (яисә) тыңлау өлешендә архив документларыннан ерактан торып файдалану хезмәтен күрсәткән өчен архив документларыннан файдаланучылардан түләү алынырга мөмкин. Күрсәтелгән хезмәтне архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә күрсәткән өчен түләү күләме, мондый түләүне алу тәртибе һәм очраклары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында архив документларыннан файдаланучыларны теркәгән, шулай ук архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмә-эзләү чараларыннан файдаланган өчен түләү алынмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 21-ТРЗ